**Республика Татарстан**
**Карашай-Сакловское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге**

---

Р Е Ш Е Н И Е — КАРАР

24 сентябрь 2020 ел — № 6

Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының» Карашай-Саклау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәм шәхси башкарма орган буларак яллаучы (эш бирүче) вәкиленә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 21 августындагы 45 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Гамәлдән чыгарырга:

Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Карашай-Саклау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм шәхси башкарма орган буларак идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керүе өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 21 августындагы 45 номерлы карарны.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Карашай-Саклау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә шәхси бердәм башкарма орган сыйфатында кире кайтарылмый торган нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 апрелендәге 88 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» карарны.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN.RU) һәм «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Карашай-Саклау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Карашай-Саклау авыл җирлеге
Советы Рәисе — В.В.Хосниева